МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

**Татарстан Республикасы муниципаль районнары башкарма комитетларының мәгариф идарәләре һәм бүлекләре җитәкчеләренә**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
IV республика конференциясе турында

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы Казан шәһәренең «Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия» гомум белем бирү учреждениесе белән берлектә күренекле драматург, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге һәм Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, халык язучысы Туфан Габдулла улы Миңнуллинның иҗади мирасын, татар әдәбиятын, мәдәниятен, сәнгатен тирәнтен өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан 2017 елның март аенда укытучыларның һәм укучыларның IV республика конференциясен оештыруы турында хәбәр итә.

Әлеге конференция 2017 нче елда татар шигъриятенең күренекле вәкиле Габделҗәббәр Кандалыйның тууына 220 ел, татар халкының танылган язучысы Галимҗан Ибраһимовның, күренекле драматург Кәрим Тинчуринның, әдәбият һәм тел галиме Җамал Вәлидинең тууларына 130 ел, әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Галимҗан Нигъмәтинең тууына 120 ел, драма артисткасы Луиза Салиаскарованың, язучылар Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази һәм Гариф Гобәйнең тууларына 110 ел тулуга һәм башка күренекле шәхесләребезнең юбилей даталарына багышлана.

Шул ук вакытта Конференция олуг әдип, татар мәгърифәтен саклау һәм үстерүгә күп көч куйган бөек милләтпәрвәр Туфан Миңнуллин идеяләрен тормышка ашыру эшендә күркәм бер чара булып тора.

Конференциядә катнашу өчен гариза, тезис һәм фәнни эш 2017 елның 20 февралена кадәр kzlar_ile@mail.ru электрон адресы буенча яки 420034, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 89А почта адресы буенча җибәрелә.

Хәбәрләшү өчен телефоннар: (843)562 25 43, 89030624954, 89179155788.

Нигезләмә: 8 биттә, 1 нөсхәдә

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр** **Э.Н.Фәттахов**

Л.Р.Зайнуллина
(843)294 95 10

Кушымта

**Туфан Миңнуллин исемендәге**
**укытучыларның һәм укучыларның**
**IV республика конференциясен үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Әлеге нигезләмә халык язучысы, күренекле драматург, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге һәм ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясен (алга таба – Конференция) үткәрү тәртибен билгели.

## II. Конференциянең максат һәм бурычлары

Конференция татар әдәбиятын, мәдәниятен, сәнгатен һәм Туфан Габдулла улы Миңнуллинның иҗади мирасын, киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелә.

Конференциянең бурычлары:

- татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру;
- яшь буында толерантлык, патриотизм хисләре тәрбияләү һәм үстерү;
- Туфан Миңнуллин әсәрләрен киңрәк өйрәнү һәм алар аша яшь буында милли үзаң тәрбияләү;
- сәләтле балаларның иҗади эшләренә бәя бирү һәм сәләтләрен үстерү.

## III. Конференцияне оештыручылар

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты;
- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Казан муниципаль берәмлеге шәһәр мәгариф идарәсе;
- Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе;
- Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры;
- Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры;
- Казан (Идел буе) федераль университеты;
- Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты;
- Татарстан Республикасы язучылар берлеге;
- Татарстан Республикасы журналистлар берлеге.

## IV. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

4.1. Конференциягә җибәрелгән фәнни-гамәли һәм иҗади эшләргә Татарстан Республикасының танылган сәнгать әһелләреннән, фән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган жюри бәя бирә.

4.2. Конференциядә катнашу бушлай. Конференциягә җибәрелгән эшләр авторларга кире кайтарылмый, әмма автор рөхсәте белән республика мәгълүмат чараларында кулланылырга мөмкин.

4.3. Конференциядә катнашу тәртибе:

Конференциядә Нигезләмә шартлары буенча билгеләнгән вакытка кадәр гариза (Кушымта 1 яки Кушымта 2) белән фәнни-гамәли һәм иҗади эшен җибәргән, Татарстан Республикасы урта һәм өстәмә белем бирү оешмаларында белем алучы 5-11 сыйныф укучылары, шулай ук мәктәп укытучылары һәм китапханәчеләре (Кушымта 3) катнаша ала.

4.4. Укучыларның фәнни-гамәли һәм иҗади эшләре һәр номинациядә түбәндәге яшь категорияләре буенча кабул ителә:

- 1 нче төркем: 5 - 7 сыйныфлар
- 2 нче төркем: 8 - 9 сыйныфлар
- 3 нче төркем: 10 - 11 сыйныфлар.

4.5. Һәр катнашучыдан билгеләнгән үрнәк буенча персональ мәгълүматларны куллануга ризалык турында белешмә тапшыру таләп ителә (Кушымта 4 - Приложение).

4.6. Конференция кысаларында түбәндәге **4 номинация** буенча секцияләр эшләячәк:

**1. Журналистика. «Кызыл тышлы дәфтәрдән».**

Журналистик язмаларның (мәкалә, интервью, репортаж, хат һ.б.) тематикасы:

1. «Татар кешесе! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Синең телеңдә катлаулы фәнни хезмәтләр дә, илаһи төшенчәләр дә, гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!» *(Т.Миңнуллин. Татарның әхлакый кодексы.).*

2. «Татар кешесе! Укы! Гыйлемле-белемле бул! Дәүләт төзү, аның белән идарә итү өчен дә, рухи һәм матди байлык туплау өчен дә аң-белем кирәк. Кушканны гына эшләүче түгел, үзең дә иҗади дәрәҗәдә эшләрлек зур белемгә ия бул.» *(Т.Миңнуллин. Татарның әхлакый кодексы.).*

Журналистик язмаларның күләме Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал белән 5-7 биттән артмаска тиеш.

**2. Драматургия. «Театр яктылыкка, нурга илтә!..». Сәхнәләштерү.**

Татар театрына нигез салынуга 110 ел тулуга багышлана.

«Театр халыкның аңын, мәдәниятен үстерә, тормышын яхшырту өчен көрәшкә әзерли». (Г.Камал).

«Татарлар бик теләп театрга йөриләр һәм аны бик яраталар икән...» (В.Г.Белинский).

«Театр – минем яшәү рәвешем... Дөньяның кызыгы минем өчен театр белән бәйләнгән...» (Т.Миңнуллин).

**XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр татар драматургиясе әсәрләреннән бер өзекне сәхнәләштерү. Регламенты 15 минут.**

**3. Драма әсәрләре һәм сценарийлар язу бәйгесе.**

Укучыларның үзләре иҗат иткән драматургия жанрындагы әсәрләр яки сценарийлар кабул ителә.

Документ создан в электронной форме. № исх-3285/16 от 14.12.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 4 из 11. Страница создана: 13.12.2016 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Бәйгегә җибәрелгән әсәрләрнең, сценарийларның күләме Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал белән 10 биттән артмаска тиеш.

**4. «Утырып уйлар уйладым».**
**Укытучылар һәм китапханәчеләр номинациясе**

Татар әдәбиятының мәктәп программасына кергән проза әсәрләренә **китапнамә** (әсәрләрне махсус видео ярдәмендә рекламалау, видеоролик ягъни **буктрейлерлар**) ясау бәйгесе.

1) Бу бәйге түбәндәге критерийлар нигезендә бәяләнә:

- сайланган әсәргә укучыларның игътибарын җәлеп итү, аларны бу әсәрне укырга этәрү көче;
- сайланган әсәрнең эчтәлеген киң һәм тирән чагылдыру;
- китапнамәнең мәгънәле, тәэсирле һәм оригиналь булуы;
- материалның этик һәм әхлакый нормалар кысаларында булуы;
- китапнамәнең техник яктан башкарылу катлаулылыгы.

2) Бу бәйгедә катнашу өчен түбәндәге таләпләр һәм шартлар куела:

- вакыты – 3 минутка кадәр;
- форматы – mpeg4, mpg, mpeg, avi;
- кулланылган материалларның (булган очракта) – текст, музыка, видео, иллюстрация һ.б. авторларын титрларда күрсәтү;
- китапнамәнең башка конкурсларда катнашмавы һәм интернет челтәреннән алынмавы.

3) Бәйгедә катнашу авторның яки авторларның эшен интернет-ресурсларда урнаштыруга ризалык булып кабул ителә.

4) Бәйгедә катнашу өчен китапнамәләр гариза белән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә kzlar_ile@mail.ru адресына һәм почта аша CD яки DVD дискта гимназия адресына җибәрелә.

4.7. Фәнни-иҗади эшләр кәгазь вариантсыз каралмый.

## V. Конференция эшләрен бәяләүгә таләпләр

- билгеләнгән теманы яктырту;
- эшкә иҗади якын килү;
- фәнни-иҗади эшнең укучы яшенә туры килүе;
- заманча компьютер технологияләрен куллану;
- югары дәрәҗәдәге осталык, яңалык, кызыклы идеяләр һ.б.;
- башка конференциядә кулланылмавы.

## VI. Конференцияне үткәрү вакыты

6.1. Конференциядә катнашу өчен гаризалар һәм эшләр 2017 елның 20 гыйнварыннан 2017 елның 20 февраленә кадәр кабул ителә.

6.2. Конференция номинацияләрендә катнашучылар фәнни һәм иҗади эшләрен тиешле гариза (Кушымта 1-3) һәм «Туфан Миңнуллин исемендәге IV республика конференциясенә» дигән язу белән Фатиха Аитова исемендәге татар

телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә **kzlar_ile@mall.ru** һәм почта буенча: **420034, ТР, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 89А** адресына эшләрнең кәгазь вариантын җибәрә.

6.3. Конференциянең журналистика, драма әсәрләре һәм сценарийлар язу, китапнамә бәйгесе 2 этапта үтә.

6.4. 1 этап – сайлап алу этабында жюри Конференциягә җибәрелгән фәнни һәм иҗади эшләрне карый һәм иң яхшыларын секцияләрдә чыгыш ясау өчен тәкъдим итә.

6.5. **Жюри эше** (2017 елның 20 февраленнан – 2017 елның 10 мартына кадәр):

- Жюри Конференция номинантларын һәм лауреатларын билгели;
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Оештыру комитеты, Конференция дипломантларына Конференциядә катнашу өчен, чакыру хаты җибәрә.

6.6. Оештыру комитеты Конференция рекламасын Татарстан Республикасы мәгълүмат чараларына, интернет порталларына бирергә хокуклы.

## VII. Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү

7.1. Журналистика, драма әсәрләре һәм сценарийлар язу, китапнамәләр төзү буенча Конференция нәтиҗәләре 2017 елның **11 мартында** билгеле була. Конференция секцияләрендә чыгыш ясаучы укучылар, укытучылар һәм китапханәчеләр исемлеге Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең сайтында һәм Бөтендөнья татар конгрессы сайтында www.tatar-congress.org **14 мартта** урнаштырыла.

7.2. Драматургия номинациясендә катнашучылар барысы да 12 нче гимназиянең Актлар залында жюри алдында чыгыш ясыйлар.

Бәйгенең уздыру вакыты: **22 мартта – Казан мәктәпләре чыгышы, 24 мартта – республика мәктәпләре чыгышы.**

7.3. Журналистика, драма әсәрләре һәм сценарийлар язу, китапнамәләр (буктрейлерлар) төзү буенча секцияләрнең эше **24 мартта** 12 нче гимназиядә уза.

7.4. Конференция аерым номинацияләрдә һәр яшь төркеме буенча иң яхшы Фәнни һәм иҗади эш авторларын дипломнар белән билгели (1, 2, 3 урыннар). Катнашучыларга шаһәдәтнамәләр электрон формада җибәрелә.

## VIII. Өстәмә мәгълүмат

Элемтәләр өчен телефоннар:
8903-062-49-54 Шәйхиева Фирая Разыйх кызы,
8917-915-57-88 Газизуллина Рәмилә Гамил кызы,
e-mail: kzlar_ile@mail.ru

Конференция турындагы мәгълүмат белән Бөтендөнья татар конгрессы сайтында www.tatar-congress.org танышырга мөмкин.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
IV республика конференциясе Нигезләмәсенә
**Кушымта 1**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның IV республика конференциясенең
**«Драматургия. Сәхнәләштерү» номинациясендә** катнашу өчен
**Гариза**

| Белем бирү оешма-сының тулы исеме | Әсәрнең исеме, авторы | Катнашучылар исемлеге | | | Житәкче-нең Ф.И.О; телефоны, электрон адресы | Декорация, музыкаль бизәлеш турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ф.И.О. | Уйнаган роле | Туган вакыты, тулы яше, сыйныфы | | |
| | | | | | | |

Сәхнәләштерелгән өзеккә бәяләмә (аннотация)

«_____ » _____________ 2017 ел.

***Искәрмә:*** *Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

Документ создан в электронной форме. № исх-3285/16 от 14.12.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 7 из 11. Страница создана: 13.12.2016 11:27

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
IV республика конференциясе Нигезләмәсенә
**Кушымта 2**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның IVреспублика конференциясендә катнашу өчен
**Гариза**

| № | Ф.И.О., авторның туган вакыты, тулы яше, сыйныфы | Автор укыган белем бирү оешмасының тулы исеме | Фәнни яки иҗади номинациясе, эшнең исеме, күләме | Авторның почта буенча тулы адресы, электрон адресы, телефоны | Җитәкченең Ф.И.О.; предметы, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Фәнни яки иҗади эшкә бәяләмә (аннотация)

«____» ___________ 2017 ел.

*Искәрмә: Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
IV республика конференциясе Нигезләмәсенә
**Кушымта 3**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның IV республика конференциясенең
**«Утырып уйлар уйладым»** номинациясендә
**(укытучылар һәм китапханәчеләр секциясе)**
катнашу өчен
**Гариза**

| № № | Ф.И.О., автор(лар)ның туган вакыты, тулы яше | Автор(лар)ның эш урыны, вазыйфасы | Китапнамәнең (буктрейлерның) исеме, күләме | Автор(лар)ның почта буенча тулы адресы, электрон адресы, телефоны | Оешма директорының Ф.И.О.; телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Фәнни-иҗади эшкә бәяләмә (аннотация)

«_____» __________ 2017 ел.

*Искәрмә: Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

Документ создан в электронной форме. № исх-3285/16 от 14.12.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 9 из 11. Страница создана: 13.12.2016 11:27

**Кушымта 4 - Приложение**

**Согласие на обработку персональных данных**

**Я,** ______________________________________________________________,
*(ФИО родителя или законного представителя)*

паспорт _____ ____________, выдан____________________________________________
*(серия, номер)* *(когда, кем)*

_____________ _________________________________________________________
*(в случае опекунства / попечительства указать реквизиты документа, на основании которого осуществляется опека или попечительство)*

______________________________________________________________________
*(адрес)*
даю согласие на обработку персональных данных моего ребенка

______________________________________________________________________
*(фамилия, имя, отчество ребенка)*

паспорт _____ _____________, выдан ________________________________________
*(серия, номер)* *(когда, кем)*
______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
*(адрес)*
оператору Министерства образования и науки Республики Татарстан для участия в конференции.

Перечень персональных данных, на обработку которых дается согласие: фамилия, имя, отчество, школа, класс, домашний адрес, дата рождения, телефон, адрес электронной почты, результаты участия в заключительном этапе конференции.

Оператор имеет право на сбор, систематизацию, накопление, хранение, уточнение, использование, передачу персональных данных третьим лицам - образовательным организациям, органам управления образованием районов (городов), Министерству образования и науки РТ, Министерству образования РФ, иным юридическим и физическим лицам, отвечающим за организацию и проведение различных этапов конференции, обезличивание, блокирование, уничтожение персональных данных.

Данным заявлением разрешаю считать общедоступными, в том числе выставлять в сети Интернет, следующие персональные данные моего ребенка: фамилия, имя, класс, школа, результат заключительного этапа конференции, а также публикацию в открытом доступе сканированной копии работы.

Обработка персональных данных осуществляется в соответствии с нормами Федерального закона Российской Федерации от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

Данное Согласие вступает в силу со дня его подписания и действует в течение 3-х лет.

_____________________ (личная подпись) _____________________ (дата)

Документ создан в электронной форме. № исх-3285/16 от 14.12.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 10 из 11. Страница создана: 13.12.2016 11:27

Лист согласования к документу № исх-3285/16 от 14.12.2016
Инициатор согласования: Зайнуллина Л. Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 13.12.2016 11:29

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 14.12.2016 - 09:38 | - |
| 2 | Исмагилова Г.Х. | | Согласовано 14.12.2016 - 10:27 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 14.12.2016 - 12:35 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Согласовано 14.12.2016 - 18:57 | - |